КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 июль г.Казань № 738

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 сентябрь, 864 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 8 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны

урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

беренче абзацта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү турында карар бер яки берничә җир кишәрлегенә карата кабул ителә.»;

1.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвестиция килешүе – Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы (алга таба – Агентлык) һәм юридик зат арасында төзелә, юридик затка Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә сатулар үткәрмичә бирелә торган җир кишәрлегендә (җир кишәрлекләрендә) (алга таба – җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре)) социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектны урнаштыруны яки масштаблы инвестиция проектын тормышка ашыруны күздә тота торган килешү;»;

дүртенче абзацта «табыш алуны үз максаты итеп куймый торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «кишәрлеген» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләрен)» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацта «кишәрлеген» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләрен)» сүзләрен өстәргә;

уникенче абзацта «кишәрлеген» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләрен)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләре турында» 2015 елның 4 августындагы 794 номерлы карарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

2.1 пунктта «кишәрлегендә» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләрендә)» сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктта:

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Оешмаларның бухгалтерлык хисаплылыгы формалары турында» 2010 елның 2 июлендәге 66н номерлы боерыгы белән расланган 0710001 нче форма буенча эшләнгән, салым органының бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын кабул итү турында билгесе куелган узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күчермәләре. Юридик зат агымдагы елда төзелгән очракта, узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын бирү таләп ителми.

Агымдагы ел чорына үз акчасы күләмен раслау сыйфатында юридик зат

югарыда күрсәтелгән форма буенча бәйсез аудит нәтиҗәләре белән расланган соңгы хисап датасына арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырырга хокуклы;»;

7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы нигезендә раслана торган салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләре үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләттә яки территориядә юридик затның теркәлмәве турында, шулай ук юридик затның түбәндәге шартларда булмавы турында мәгълүмат бирелгән, юридик затның җитәкчесе тарафыннан расланган декларация:

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булу, юридик затка карата банкротлык процедурасы билгеләнү;

юридик затның мөлкәтенә арест салыну яки аның өчен түләтү;

юридик затның хуҗалык эшчәнлеге туктатылу яисә законнар белән билгеләнгән тәртиптә туктатып торылу;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм (яки) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре алдында акча йөкләмәләре, шул исәптән бюджет кредитлары буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурыч булу;

хезмәт хакы буенча бурыч булу;

юридик зат дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә алып барыла торган намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату аукционында, йә Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында булу;»;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) проектны тормышка ашыруны (объект урнаштыруны) финанслау мөмкинлеген раслый, шул исәптән үз акчасы булуны раслый торган документлар.

Юридик зат – проект инициаторының үз акчасы күләме Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Оешмаларның бухгалтерлык хисаплылыгы формалары турында» 2010 елның 2 июлендәге 66н номерлы боерыгы белән расланган 0710001 нче форма буенча эшләнгән, салым органының бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын кабул итү турында билгесе куелган узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының III нче «Капитал һәм резервлар» бүлеге йомгагында раслана.

Агымдагы ел чорына үз акчасы күләмен раслау сыйфатында юридик зат югарыда күрсәтелгән форма буенча бәйсез аудит нәтиҗәләре белән расланган соңгы хисап датасына арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырырга хокуклы.

Проект торак урыннарның гомуми мәйданы кимендә 5 мең кв.метрлы күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар) һәм (яки) башка капиталь төзелеш объектларын төзүне күздә тота торган «Күпфатирлы йортлар төзү өчен акчасы җәлеп ителгән, намуссыз йорт төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрү (Россия Федерациясе Җир

кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының $3^1$ пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) бирү очракларыннан тыш)» критерие буенча тормышка ашырылган очракта, юридик затның раслана торган үз акчасы күләме бизнес-план буенча инвестицияләр күләменең кимендә 5 проценты күләмендә билгеләнә.

Төзелә торган сәнәгать (индустриаль) паркының идарә итүче компаниясеннән үтенечнамә кергән очракта, үз акчасы булу идарә итүче компаниянең үз акчасы белән йә сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резидентларының үз акчасы белән раслана. Үз акчасының раслана торган күләме идарә итүче компаниянең бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын (бизнес-планда сәнәгать (индустриаль) паркының кирәкле инфраструктурасын (коммуникацияне кертеп) булдыру, склад, сәнәгать, административ-эшлекле һәм башка инфраструктура булдыру карала торган шарт белән) йә сәнәгать (индустриаль) паркының һәр потенциаль резидентының бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Проектны тормышка ашыруның (объектны урнаштыруның) башка очракларында, юридик зат – проект инициаторының раслана торган үз акчасы күләме инвестицияләр күләменең кимендә 30 проценты күләмендә йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) агымдагы кадастр кыйммәтеннән ким булмаган күләмдә билгеләнә;»;

10 пунктчаның дүртенче абзацында «кишәрлегенең» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләренең)» сүзләрен өстәргә;

11 пунктчада «кишәрлегенә» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләренә)» сүзләрен өстәргә;

12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) территориясендә җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) урнашкан җирле үзидарә органының түбәндәгеләрне нигезли торган мәгълүматы:

инвестиция проектының стратегик планлаштыру документларында (объектны урнаштыру өчен) билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килүен;

җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) объектны урнаштыру өчен стратегик планлаштыру документларында билгеләнгән билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килүен;

бирелә торган җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) мәйданының туры килүен, шулай ук проектны тормышка ашыру (объектны урнаштыру) өчен аны яки аларны бирү мөмкинлеген;»;

13 пунктчада тиешле килешләрдәге «кишәрлеге» сүзен тиешле килешләрдәге «кишәрлеге (җир кишәрлекләре)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

бишенче абзацта «кишәрлеген» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләрен)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «кишәрлеген» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләрен)» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«проектны тормышка ашыру (объектны урнаштыру) өчен җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) мәйданының бу Тәртипнең 2.3 пунктындагы 12 һәм 13 пунктчалары нигезендә тапшырылган документларга туры килмәве, шулай ук Россия Федерациясе

Җир кодексының 39[16] статьясында күрсәтелгән башка нигезләр.»;

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мотивлаштырылган бәяләмә проектын карап тикшергәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яки Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) белән эш итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы проектны анық максатлары һәм бурычлары нигезендә гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) бирүгә ризалыкны раслый.»;

2.12 пунктта «кишәрлеге» сүзен «кишәрлеге (җир кишәрлекләре)» сүзләренә алмаштырырга;

2.13 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «теркәп,» сүзеннән соң «һәм имзаланган инвестиция килешүенең күчермәсе белән» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта татар текстында «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта татар текстында «кишәрлегенең» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләренең)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

2.14 пунктта татар текстында «теркәп,» сүзеннән соң «һәм имзаланган инвестиция килешүенең күчермәсе белән» сүзләрен өстәргә;

2.15 пунктта «кишәрлеге» сүзен «кишәрлеге (җир кишәрлекләре)» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның «а» пунктчасында «кишәрлеге» сүзен «кишәрлеге (җир кишәрлекләре)» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта:

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Оешмаларның бухгалтерлык хисаплылыгы формалары турында» 2010 елның 2 июлендәге 66н номерлы боерыгы белән расланган 0710001 нче форма буенча эшләнгән, салым органының бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын кабул итү турында билгесе куелган узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күчермәсен. Юридик зат агымдагы елда төзелгән очракта, узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын бирү таләп ителми.

Агымдагы ел чорына үз акчасы күләмен раслау сыйфатында юридик зат югарыда күрсәтелгән форма буенча бәйсез аудит нәтиҗәләре белән расланган соңгы хисап датасына арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырырга хокуклы;»;

6 пунктчада «җыемнар» сүзеннән соң «, иминият кертемнәре» сүзләрен өстәргә;

7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы нигезендә раслана торган салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләре үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә

кертелгән дәүләттә яки территориядә юридик затның теркәлүе турында, шулай ук юридик затның түбәндәге шартларда булмавы турында мәгълүмат бирелгән, юридик затның җитәкчесе тарафыннан расланган декларация:

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булу, юридик затка карата банкротлык процедурасы билгеләнү;

юридик затның мөлкәтенә арест салыну яки аның өчен түләтү;

юридик затның хуҗалык эшчәнлеге туктатылу яисә законнар белән билгеләнгән тәртиптә туктатып торылу;

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм (яки) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре алдында акча йөкләмәләре, шул исәптән бюджет кредитлары буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурыч булу;

хезмәт хакы буенча бурыч булу;

юридик зат дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә алып барыла торган намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату аукционында, йә Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында булу;»;

8 пунктчада «проектны тормышка ашырганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) проектны тормышка ашыруны (объектны урнаштыруны) финанслау мөмкинлеген раслый, шул исәптән үз акчасы булуны раслый торган документлар.

Юридик зат – проект инициаторының үз акчасы күләмеРоссия Федерациясе Финанс министрлыгының «Оешмаларның бухгалтерлык хисаплылыгы формалары турында» 2010 елның 2 июлендәге 66н номерлы боерыгы белән расланган 0710001 нче форма буенча эшләнгән, салым органының бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын кабул итү турында билгесе куелган узган ел өчен еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының III нче «Капитал һәм резервлар» бүлеге йомгагында раслана.

Агымдагы ел чорына үз акчасы күләмен раслау сыйфатында юридик зат югарыда күрсәтелгән форма буенча бәйсез аудит нәтиҗәләре белән расланган соңгы хисап датасына арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырырга хокуклы.

Проект торак урыннарның гомуми мәйданы кимендә 5 мең кв.метрлы күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар) һәм (яки) башка капиталь төзелеш объектларын төзүне күздә тота торган «Күпфатирлы йортлар төзү өчен акчасы җәлеп ителгән, намуссыз йорт төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрү (Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының $3^1$ пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) бирү очракларыннан тыш)» критерие буенча тормышка ашырылган очракта, юридик затның раслана торган үз акчасы күләме бизнес-план буенча инвестицияләр күләменең кимендә 5 проценты күләмендә билгеләнә.

Төзелә торган сәнәгать (индустриаль) паркының идарә итүче компаниясеннән үтенечнамә кергән очракта, үз акчасы булу идарә итүче компаниянең үз акчасы белән йә сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резидентларының үз акчасы белән раслана. Үз акчасының раслана торган күләме идарә итүче компаниянең бизнес-

планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын (бизнес-планда сәнәгать (индустриаль) паркының кирәкле инфраструктурасын (коммуникацияне кертеп) булдыру, склад, сәнәгать, административ-эшлекле һәм башка инфраструктура булдыру карала торган шарт белән) йә сәнәгать (индустриаль) паркының һәр потенциаль резидентының бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Башка проектны тормышка ашыру (объект урнаштыру) очракларында, юридик зат – проект инициаторының раслана торган үз акчасы күләме инвестицияләр күләменең кимендә 30 проценты күләмендә йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) агымдагы кадастр кыйммәтеннән ким булмаган күләмдә билгеләнә;»;

10 пунктчада «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) территориясендә җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) урнашкан җирле үзидарә органының түбәндәгеләрне нигезли торган мәгълүматы:

җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) объектны урнаштыру өчен стратегик планлаштыру документларында билгеләнгән билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килүен;

бирелә торган җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) мәйданының туры килүен, шулай ук проектны тормышка ашыру (объектны урнаштыру) өчен аны яки аларны бирү мөмкинлеген;»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пунктча өстәргә:

«$11^1$) проект «Күпфатирлы йортлар төзү өчен акчасы җәлеп ителгән, намуссыз йорт төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрү (Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының $3^1$ пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) бирү очракларыннан тыш)» критерие буенча тормышка ашырылган очракта, юридик зат тарафыннан үтенеч язуы составында шулай ук түбәндәгеләр тапшырыла:

территориясендә күпфатирлы йорт урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы, юридик зат – проект инициаторы, балансында күпфатирлы йорт булган юридик зат һәм башка кызыксынучы затлар арасында зыян күргән гражданнарга ярдәм итү буенча чара (чаралар) күрү турында килешү (зыян күргән гражданнарның хокукларын торгызу турында килешү);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм (яки) «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәяләр билгеләү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан территориясендә күпфатирлы йорт урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы белән бергә зыян күргән гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча чара (чаралар) күрү чыгымнары күләмен бәяләү;

«Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә бәяләүче тарафыннан башкарылган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләү турында хисап;»;

12 пунктчада тиешле килешләрдәге «кишәрлеге» сүзен тиешле килешләрдәге «кишәрлеге (җир кишәрлекләре)» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

5.1 пунктта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

5.2 пунктның беренче абзацында «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) арендасы шартнамәсенә Россия Федерациясе законнарында һәм җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) арендасы шартнамәсендә каралган тәртиптә һәм шартларда үзгәреш кертелергә яки аның гамәлдә булуы туктатылырга мөмкин.

Арендага бирелгән җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) субарендага бирүне, шулай ук җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) арендасы шартнамәсе буенча үз хокукларын һәм йөкләмләрен өченче затка аренда шартнамәсе срогы чикләрендә тапшыруны (җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) сәнәгать (индустриаль) паркының идарә итүче компаниясе тарафыннан сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резидентларына субарендага бирелү очракларыннан тыш) килештерү мәсьәләләрен карап тикшерү бу Тәртипнең 2.5 – 2.15 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5.4 пунктта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктта «кишәрлеге» сүзеннән соң «(җир кишәрлекләре)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасында:

1.3 пунктта татар тектсында «Арендатор» сүзе алдына «Идарә итүче компания булмаган» сүзләрен өстәргә;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1.2 пунктча өстәргә:

«4.1.2. Әгәр Сәнәгать (индустриаль) паркының идарә итүче компаниясе – җир кишәрлеген арендага алучы, ә сәнәгать (индустриаль) паркының потенциаль резиденты җир кишәрлеген субарендага алучы булса, җир кишәрлеген субарендага тапшырырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин